ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

01 апрель 2026 ел № 359

**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Махсус хәрби операциядә катнашу максатларында Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзүдә ярдәм иткән затларга Россия Федерациясе гражданының (чит ил гражданының) бер мәртәбә бирелә торган акчалата түләү бирү тәртибен раслау хакында» 2025 елның 16 июлендәге 782 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Галәүтдинова Әлфия Салих кызын Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары вазыйфасына билгеләп куюга бәйле рәвештә, Нурлат муниципаль районы Башлыгының 2026 елның 17 мартындагы 05л номерлы карарына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 16 июлендәге 782 номерлы карары белән расланган (Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 23 июлендәге 817 номерлы, 2026 елның 19 гыйнварындагы 34 номерлы карары редакциясендә) Россия Федерациясе гражданының (чит ил гражданының) махсус хәрби операциядә Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзүдә ярдәм иткән затларга бердәм акчалата түләүне билгеләү комиссиясе составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Әлфия Салих кызы Галәүтдиновага карата «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары вазифаларын башкаручы» вазифасын «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары» дип алыштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе җаваплылыгында калдырырга.

Җитәкче Ә.К. Габдуллин